**РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-02-22, факс (85552) 3-13-44, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.r

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

__________ № _________

**Актаныш муниципаль районында
санитар-экологик икеайлык үткәрү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023елның 14 мартындагы 625-р номерлы боерыгын үтәү йөзеннән һәм Актаныш муниципаль районының торак пунктлары территорияләрен санитар чистарту мәсьәләсен хәл итү һәм аларны халыкның санитар-эпидемиологик һәм экологик иминлеге таләпләренә җавап бирә торган халәткә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Башкарма комитеты

**БОЕРА:**

1. 2023 елның 01 апреленнән 31 маена кадәр торак пунктларны санитар чистарту, яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча санитар-экологик икеайлык (алга таба - икеайлык) игълан итәргә.
2. Район территориясен төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча эшләрне координацияләү һәм оештыру өчен Актаныш муниципаль районы оператив штабы составын булдырырга һәм расларга (1 нче кушымта ).
3. Торак пунктларны санитар чистарту, яшелләндерү һәм төзекләндерү чаралары планын расларга (2 нче кушымта).
4. Авыл җирлекләре башлыкларына, районның авыл хуҗалыгы формированиеләре, предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- икеайлык чорында эшләрне координацияләү өчен урыннарда оператив штаблар булдырырга;
- авыл җирлекләре территорияләрен чистарту, төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча кичектергесез чаралар күрергә;
- 2023 елның 1 апреленә кадәр үз территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту буенча чаралар планын эшләргә;
- агач һәм куаклар утыртуга, киселгән кишәрлекләрдә агачларны яңартуга аерым игътибар бирергә;
- җир кишәрлекләре янәшәсендәге санитар зоналарны конкрет җирдән файдаланучыларга беркетергә;
- обелискларны, һәйкәлләрне һәм аның янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерүне һәм ремонтлауны 2023 елның 1 маена тәгәлләргә;
- билгеләнгән санитар-экологик чараларны үтәүгә халыкны җәлеп итү буенча даими рәвештә аңлату һәм оештыру эшләре алып барырга;

- территорияләрне төзелеш чүп-чарыннан вакытында чистартуны тәэмин итәргә;

- ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар-экологик чистарту эшенә ирекле нигездә җәлеп итү;

- 2023 елның 15 маена кадәр үз территорияләрендә рөхсәтсез калдыклар урнаштыру урыннарын бетерү буенча кичекмәстән чаралар күрергә;

- су объектларының, паркларның, балалар мәйданчыкларының су саклау зоналарын, халыкның күпләп ял итү урыннарын, хосусый торак сектор территорияләрен, автомобиль юлларының юл буе полосаларын санитар чистарту, контейнер мәйданчыкларын төзү һәм ремонтлау, каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар әзерләү һәм ремонтлау чараларын үткәрергә;

- чүп-чарны чыгару һәм кабул итү полигоннарны буенча, сортлау һәм күмү буенча махсус коммуналь техниканың нәтиҗәле эшен тәэмин итәргә;

- калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын юкка чыгару мониторингын «Татарстан Республикасының экологик картасы» геомәгълүмат системасы аша http://ecokarta.tatar.ru/ тормышка ашырырга.

5. 2023 елның 23 апрелендә район территориясен санитар чистарту буенча гомуми район шимбә өмәсе игълан итәргә.

6. Район оператив штабына:

- урыннарда уздырыла торган эшләрнең барышын даими рәвештә җитәкчелек итүне һәм тикшереп торуны оештырырга;

- атна саен җитәкчеләрнең планеркаларында, киңәшмәләрендә башкарылган эшләргә йомгак ясарга.

7. Татарстан Республикасында экологик иминлекне, табигатьтән файдалануны һәм санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итү буенча ведомствоара комиссиягә әлеге карарның 1нче кушымтасы нигезендәге форма буенча икеайлыкны үткәрү барышы турында әлеге карарга 2 нче кушымта формасы (аңлатма язуы кушымтасы белән) буенча атна саен чәршәмбе көнне  - 2023 елның 6, 20 апрелендә, 4, 18 һәм 25 маенда.мәгълүмат тапшырырга.

8. «Актаныш таннары» газетасы редакциясенең Татмедиа ААҖ филиалына, җирле радиотапшыруларга район оператив штабы, авыл җирлекләре советлары, предприятиеләр, оешмалар, чистарту, төзекләндерү, территорияләрне яшелләндерү һәм эшләнгән чараларның үтәлешен тәэмин итү буенча учреждениеләр эшчәнлеген системалы һәм оператив яктыртуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

9. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А. Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты боерыгына
_______________ 2023 ел №_____,
кушымта

Актаныш муниципаль районы территориясен санитар чистарту буенча икеайлык үткәрү буенча район штабы составы

| | |
|---|---|
| Ильясов Р.А. | - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, штаб рәисе; |
| | |
| Штаб әгъзалары: | |
| Гарипов Р.И. | Инфраструктур үсеш буенча муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Хафизова Л.М. | - Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре баш дәүләт санитария табибының Актаныш муниципаль районы буенча урынбасары; |
| Фәрукшин Р.А. | - Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Кама буе территориаль идарәсенең әйдәп баручы белгече; |
| Шәмсиев Р.Р. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлекчәсе башлыгы, полиция капитаны. |
| Шакирова Р. М. | - Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Латыйпов Н.Н. | - Башкарма комитетның социаль һәм агарту эшләре бүлеге башлыгы; |
| Хәев А. Р. | - «Актаныш район үзәк хастаханәсе» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы; |
| Зарипова А.И. | - АМР Башкарма комитетының административ комиссиясенең җаваплы секретаре; |
| Галиәхмәтов А. К. | - АМР Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| | |
| И.Ш. Хуҗәхмәтов | - «Яран» ТМШ директоры; |

Авыл җирлекләре башлыклары

*Башкарма комитет җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган затлар, килешү буенча, штаб составына кертелә.

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты боерыгына
__________ 2023 ел, №____
кушымта

**2023 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр санитар-экологик икеайлык вакытында Актаныш муниципаль районы территориясен чистарту буенча чаралар планы**

| № | Чараның атамасы | Башкару срогы | Җаваплы затлар |
|---|---|---|---|
| 1. | Предприятие, учреждение һәм башка оешма җитәкчеләренә һәм халыкка икеайлык үткәрү турында мәгълүмат җиткерү | март | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, массакүләм мәгълүмат чаралары (килешү буенча) |
| 2. | Икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаб булдыру | март | ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 3. | Муниципаль районның административ комиссиясе эшен активлаштыру торак пункт территорияләрен төзекләндерүнең билгеләнгән кагыйдәләрен аңлату өлешендә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша, һәм аларны бозган өчен җаваплылык | Апрель-май | ТР Актаныш муниципаль районының административ комиссиясе рәисе |
| 4. | Чүп-чар чыгару буенча махсус коммуналь техниканың нәтиҗәле эшләвен, шулай ук каты көнкүреш калдыкларын кабул итү, сортларга аеру һәм күмү полигонының эшен тәэмин итү | Апрель-май | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, «Актаныш полигон ТБО» МУП килешү буенча; |
| 5. | Актаныш районы һәм авыл җирлекләре территорияләрен, гомуми файдаланудагы юл буе полосаларын, баганалар агарту буенча атналык шимбә өмәләре үткәрү | шимбә көннә рендә | Авыл җирлекләре башлыклары, Актаныш авыл җирлеге җитәкчесе - килешү буенча; предприятие һәм учреждение җитәкчеләре, килешү буенча; |
| 6. | Янәшәдәге территорияләрне предприятиеләрне һәм учреждениеләрне чистарту буенча атналык чәршәмбе өмәләре үткәрү | һәр чәршәмбе | Авыл җирлеге башлыклары- килешү буенча; предприятие һәм учреждение җитәкчеләре - килешү буенча; |
| 7. | Чүп-чардан чистарту һәм төзекләндерү<br>- Җиңү паркы,<br>- Мәдәният һәм ял паркы,<br>-Буалар | Апрель | Актаныш авыл җирлеге җитәкчесе, килешү буенча, предприятие һәм учреждение җитәкчеләре килешү буенча; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Сабантуй мәйданындагы урманнар<br>- Иске Идел яр буе | | |
| 8. | Җирлекләр территорияләрендә рөхсәтсез чүплекләрне бетерү | Апрель-май | Авыл җирлекләре башлыклары, Актаныш авыл җирлеге җитәкчесе - килешү буенча; |
| 9. | Иске агачларны кисү, куакларны һәм агачларны декоратив кисү | Апрель-май | Авыл җирлекләре башлыклары, Актаныш авыл җирлеге җитәкчесе |
| 10. | Контейнерлар мәйданчыкларын төзекләндерү, контейнерларны ремонтлау һәм буяу | Апрель | Авыл җирлекләре башлыклары, Актаныш авыл җирлеге җитәкчесе - килешү буенча; «Яран» торак милекчеләре ширкәте директоры |
| 12. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның эшен активлаштыру (ТР КоАП 3.6 ст.). | Апрель-май | Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар (ТР КоАП 3.6 статьясы буенча) |
| 13. | «Урман һәм бакча айлыгы» акциясе кысаларында агач утырту | Апрель-май | Авыл җирлекләре башлыклары, Актаныш авыл җирлеге җитәкчесе - килешү буенча; оешмалар һәм учреждениеләр - килешү буенча; |
| 14. | «Агачларны бергә үстерәбез!» мәктәпкәчә, гомуми белем бирү учреждениесе территорияләрендә балалар белән бергә агачлар утырту | Апрель-май | Мәгариф бүлеге, гомуми белем бирү учреждениеләре - килешү буенча; |
| 15. | «Иң чиста торак пункт», «Иң төзекләндерелгән оешма территориясе», «Өмәләрне иң яхшы оештыру (җитәкчеләр бәяләнә)» конкурслары үткәрү | Апрель-май | АМР Советы, Башкарма комитеты |
| 16. | Икеайлык вакытында чаралар планын үтәүнең атналык маниторингы | Апрель-май | Штаб башлыгы |
| 17. | «Актаныш таннары» район газетасы битләрендә һәм «Актаныш хәбәрләре» телекомпаниясе чыгарылышларында планны гамәлгә ашыру барышын яктырту | Апрель-май | «Актаныш таннары» район газетасы редакциясе; «Актаныш хәбәрләре» телекомпаниясе, килешү буенча |